КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 5 май г.Казань № 310

2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразын эшләү графигын раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразын эшләү графигын (алга таба – График, Фараз) расларга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына График нигезендә үз юнәлешләре буенча фараз күрсәткечләрен бирүне һәм «Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше» дәүләт мәгълүмат-аналитика системасына (алга таба – Система) кертүне тәэмин итәргә.

3. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына, Татарстан Республикасында үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының соратулары буенча Фаразны эшләү өчен кирәкле мәгълүматны билгеләнгән тәртиптә җибәрүне;

Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына Графикта билгеләнгән сроклар нигезендә Системага фараз күрсәткечләрен кертүне гамәлгә ашыруны;

Татарстан Республикасында үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга җитештерү-финанс эшчәнлеге буенча фараз күрсәткечләрен Системага кертүне гамәлгә ашыруны.

4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары соратулар җибәргәндә һәм мәгълүматны Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнарына керткәндә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән мәгълүматны саклау режимы тәэмин ителергә тиеш дип билгеләргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 5 май, 310 нчы
карары белән расланды

2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразын эшләү
графигы

| Т/с | Материаллар һәм документлар, чаралар исеме | Җаваплы башкаручы | Тапшыру вакыты | Кайсы оешмага кертелүе |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| I. Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгына кертү өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Уртача вакытка исәпләнгән чорга Россия Федерациясен социаль-икътисадый үстерү фаразын эшләү, аңа төзәтмәләр кертү, аның мониторингын гамәлгә ашыру һәм аны тикшерүдә тоту тәртибе һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым актлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2015 ел, 14 ноябрь, 1234 нче карары нигезендә 2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразын эшләү | | | | |
| 1. | Тиешле исәп-хисаплар, нигезләүләр һәм аңлатма язуы белән, вариантларга (консерватив, база, максатчан) бүлеп, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы формасы (2п формасы) бүлекләре буенча 2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразы: | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республи- | 2021 елның 22 июненә кадәр – якынча, 2021 елның 22 октябренә кадәр – тәгаенләнгән | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, «Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше» дәүләт мәгълүмат-аналитика системасы (алга таба – Система) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | касы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты | | |
| 1.1. | Халык | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2021 елның 22 июненә кадәр – якынча, 2021 елның 22 октябренә кадәр – тәгаенләнгән | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 1.2. | Сәнәгать җитештерүе, продукциянең иң мөһим төрләрен табигый рәвештә җитештерү:<br>төяп җибәрелгән продукция күләме, сәнәгать җитештерүе индексы, дефлятор индекс– Татарстан Республикасы буенча, шул исәптән икътисадый эшчәнлек төрләре буенча барлыгы;<br>продукциянең иң мөһим төрләрен табигый рәвештә җитештерү (шул исәптән предприятиеләр яктылыгында) | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | 2021 елның 22 июненә кадәр – якынча, 2021 елның 22 октябренә кадәр – тәгаенләнгән | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 1.2.1. | Икътисадый эшчәнлек төрләре буенча төяп җибәрелгән продукция күләме, сәнәгать җитештерүе индексы, дефлятор индекс:<br>башка файдалы казылмаларны чыгару;<br>пар белән тәэмин итү;<br>һаваны кондиционерлау;<br>су белән тәэмин итү; | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы | 2021 елның 15 июненә кадәр – якынча, 2021 елның 18 октябренә кадәр – тәгаенләнгән | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Система |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | су чыгару, калдыклар җыюны һәм утилизацияләүне оештыру, пычракларны бетерү эшчәнлеге;<br>металл булмаган башка минераль продукция җитештерү;<br>продукциянең иң мөһим төрләрен табигый рәвештә җитештерү | | | |
| 1.2.2. | «Азык-төлек продуктлары җитештерү» икътисадый эшчәнлек төре буенча төяп җибәрелгән продукция күләме, сәнәгать җитештерүе индексы, дефлятор индекс;<br>продукциянең иң мөһим төрләрен табигый рәвештә җитештерү | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | 2021 елның 15 июненә кадәр – якынча, 2021 елның 18 октябренә кадәр – тәгаенләнгән | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Система |
| 1.2.3. | «Компьютерлар, электрон һәм оптик эшләнмәләр җитештерү» икътисадый эшчәнлек төре буенча төяп җибәрелгән продукция күләме, сәнәгать җитештерүе индексы, дефлятор индекс | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы | 2021 елның 15 июненә кадәр – якынча, 2021 елның 18 октябренә кадәр – тәгаенләнгән | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Система |
| 1.3. | Электр энергиясенә уртача тарифлар | Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты | 2021 елның 22 июненә кадәр – якынча, 2021 елның 22 октябренә кадәр – тәгаенләнгән | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 1.4. | Авыл хуҗалыгы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | 2021 елның 22 июненә кадәр – якынча, 2021 елның 22 октябренә кадәр – тәгаенләнгән | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 1.5. | Төзелеш | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | 2021 елның 22 июненә кадәр – якынча, 2021 елның 22 октябренә кадәр – тәгаенләнгән | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 1.6. | Транспорт | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы | 2021 елның 22 июненә кадәр – якынча, 2021 елның 22 октябренә | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | кадәр – тәгаенләнгән | |
| 1.7. | Элемтә | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы | 2021 елның 22 июненә кадәр – якынча, 2021 елның 22 октябренә кадәр – тәгаенләнгән | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 1.8. | Сәүдә һәм халыкка хезмәт күрсәтү | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | 2021 елның 22 июненә кадәр – якынча, 2021 елның 22 октябренә кадәр – тәгаенләнгән | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 1.9. | Тышкы икътисадый эшчәнлек | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | 2021 елның 22 июненә кадәр – якынча, 2021 елның 22 октябренә кадәр – тәгаенләнгән | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 1.10. | Берләштерелгән бюджет | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы | 2021 елның 22 июненә кадәр – якынча, 2021 елның 22 октябренә кадәр – тәгаенләнгән | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 1.11. | Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2021 елның 22 июненә кадәр – якынча, 2021 елның 22 октябренә кадәр – тәгаенләнгән | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 1.12. | 2022 – 2024 елларга ведомство буйсынуындагы предприятиеләр эшчәнлегенең төп күрсәткечләре фаразы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Рес- | 2021 елның 15 июненә кадәр | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | публикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы | | |
| 1.13. | 2021, 2022 елларда сәнәгать продукциясен җитештерүнең артуын исәпләү (ведомство буйсынуындагы предприятиеләр ягында) | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | 2021 елның 22 июненә кадәр | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| «2. | Аңлатма язуы белән 2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразы (2п формасы) | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | 2021 елның 20 июленә кадәр – якынча, 2021 елның 10 ноябренә кадәр – тәгаенләнгән | Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы, «Идарә» дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасы |
| II. Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштыру өчен 2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразының төп параметрларын эшләү | | | | |
| 1. | Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары һәм предприятиеләре (оешмалар)ы вәкилләре катнашында Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразларын формалаштыру буенча ведомствоара эшче төркем утырышларын үткәрү | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы (килешү буенча), муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2021 елның июне | |
| «2. | Тиешле исәп-хисаплар, нигезләүләр һәм аңлатма язуы белән 2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасының шәһәр округларын, муниципаль районнарын һәм җирлекләрен социаль-икътисадый | Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2021 елның 11 июненә кадәр | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | үстерү фаразлары | | | |
| 3. | 2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасы буенча фараз күрсәткечләре, 2021 елгы бәя, 2020 ел өчен факттагы күрсәткечләр, шул исәптән:<br>тулаем төбәк продукты күләме һәм динамикасы;<br>инфляция дәрәҗәсе;<br>икътисадның база тармаклары динамикасы;<br>продукциянең төп төрләрен җитештерү күләме;<br>бухгалтерлык исәбе максатлары өчен оешмалар табышы;<br>узган елга карата төп капиталга инвестицияләр күләме һәм үсеш темплары;<br>узган елга карата ваклап сату әйләнеше һәм үсеш темплары;<br>узган елга карата халыкка түләүле хезмәтләр күрсәтү күләме һәм үсеш темплары;<br>сумның АКШ долларына курсы;<br>«Юралс» чи маркадагы нефтькә бәя;<br>узган елга карата эш хакы фонды һәм үсеш темплары;<br>узган елга карата уртача эш хакы һәм үсеш темплары;<br>җан башына исәпләгәндә яшәү минимумы күләме | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | 2021 елның 5 июленә кадәр | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы |
| «4. | 2022 – 2024 елларга фараз күрсәткечләр, 2021 елгы бәя, муниципаль районнар һәм шәһәр округлары яктылыгында 2020 елгы фактагы күрсәткечләр, шул исәптән:<br>тулаем территориаль продукт күләме;<br>сәнәгать продукциясе җитештерүгә;<br>узган елга карата эш хакы фонды (шул исәптән җирлекләр буенча) һәм үсеш темплары;<br>узган елга карата предприятиеләр һәм оешмалар | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | 2021 елның 5 июленә кадәр | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | хезмәткәрләренең уртача исемлек саны, үсеш темплары;<br>узган елга карата уртача эш хакы (шул исәптән җирлекләр буенча) һәм үсеш темплары;<br>узган елга карата ваклап сату әйләнеше һәм үсеш темплары | | | |
| «5. | Нигезләүләр һәм аңлатма язуы белән 2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасы икътисады секторларын үстерү фаразының төп күрсәткечләре: | | | |
| 5.1. | Төяп җибәрелгән продукция (эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләр) күләме, сәнәгать җитештерүе индексы;<br>ведомство буйсынуындагы предприятиеләр яктылыгында сәнәгать продукциясенең мөһим төрләрен җитештерү | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | 2021 елның 24 августына кадәр | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 5.1.1. | Төяп җибәрелгән продукция (эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләр) күләме, сәнәгать җитештерүе индексы;<br>ведомство буйсынуындагы предприятиеләр яктылыгында сәнәгать продукциясенең иң мөһим төрләрен җитештерү (бу графикның 1.2 пунктында билгеләнгән тәртип нигезендә) | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсе цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы | 2021 елның 18 августына кадәр | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Система |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 5.2. | 2021, 2022 елларда сәнәгать продукциясен җитештерүнең артуын исәпләү (ведомство буйсынуындагы предприятиеләр яктылыгында) | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | 2021 елның 24 августына кадәр | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 5.3. | Узган елга карата ваклап сату әйләнеше, үсеш темплары;<br>узган елга карата җәмәгать туклануы әйләнеше, үсеш темплары | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | 2021 елның 24 августына кадәр | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 5.4. | Тышкы икътисадый эшчәнлек:<br>товарлар экспорты;<br>товарлар импорты | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | 2021 елның 24 августына кадәр | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 5.5. | Узган елга карата авыл хуҗалыгы продукциясе күләме, үсеш темплары;<br>авыл хуҗалыгы продукциясенең һәм агросәнәгать комплексында эшкәртү сәнәгатенең төп төрләрен җитештерү | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | 2021 елның 24 августына кадәр | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 5.6. | Узган елга карата «төзелеш» эшчәнлек төре буенча башкарылган эшләр күләме, үсеш темплары;<br>барлык финанслау чыганаклары исәбеннән, шул исәптән социаль ипотека программасы буенча торак йортларны файдалануга тапшыру;<br>халыкның гомуми торак мәйданы белән тәэмин ителеше (җан башына исәпләгәндә) | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | 2021 елның 24 августына кадәр | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 5.7. | Теркәлгән эшсезләр саны (чор ахырына);<br>теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе (чор ахырына) | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2021 елның 24 августына кадәр | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |
| 5.8. | 2022 – 2024 елларга ведомство буйсынуындагы предприятиеләр эшчәнлеге буенча төп күрсәткечләрнең төгәенләнгән фаразы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзе- | 2021 елның 24 августына кадәр | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | леш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы | | |
| 6. | Татарстан Республикасы Президентының Бюджет юлламасы проектына материаллар, шул исәптән:<br>2021 елның үткән чоры өчен Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше буенча якынча йомгаклар һәм 2021 ел өчен социаль-икътисадый үсеш буенча көтелә торган йомгаклар;<br>2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразы | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | 2021 елның 10 сентябренә кадәр | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы |
| 7. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышы өчен 2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразы һәм 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразы турында материаллар | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | сентябрь, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының эш планы нигезендә | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты |
| 8. | 2021 елда Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү буенча төп күрсәткечләрне бәяләү | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2021 елның 13 декабренә кадәр | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Система |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 9. | Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразын эшләү өчен кирәкле статистика мәгълүматы | Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы (килешү буенча) | ел дәвамында | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Система |